СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2020 Әгерҗе шәһәре № 3-9

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында территорияләрне су басу һәм су ташу зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен туктатып тору турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Граждан кодексының 611 ст.1 п.п., 612 ст., 614 п. нигезендә, Су ресурслары федераль агентлыгы (Росводресурслар) Түбән Идел бассейны су идарәсенең “1 % тәэмин ителешле су басулар һәм ташулар вакытында Татарстан Республикасы, Әгерҗе шәһәре чикләрендә Әгерҗе елгасы янында, Бола елгасы янында, Буа муниципаль районының Бик-Үти авылы чикләрендә, Нурлат муниципаль районының Бурметьево авылы чикләрендә Олы Чирмешән елгасы янында, Лениногорск муниципаль районының Иске Письмянка авылы чикләрендә Дала Зәе елгасы янында, Урсалинка елгасына таба, Әлмәт шәһәренең Урсалы микрорайоны чикләрендә, Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авылы чикләрендә Чишмә елгасына кадәр территорияләрне су басу һәм су ташу зоналары чикләрен билгеләү турында” 2019 елның 20 декабрендәге 617 номерлы боерыгын исәпкә алып, су басу зоналары чикләрендә яңа объектлар төзүне тыюны һәм арендага алучыга бәйле булмаган хәлләр аркасында арендага алу мөлкәтеннән файдаланып булмау мөмкинлеген һәм арендаторны аренда түләвен кертү бурычын үтәүдән азат итүне исәпкә алып, шулай ук муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, аны Россия Федерациясе законнарына һәм норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1 % тәэмин ителешле су басулар һәм ташулар вакытында су басу һәм су ташу зоналары чикләрендә урнашкан территорияләрдәге җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча Су ресурслары федераль агентлыгының (Росводресурслар) Түбән Идел бассейны су идарәсенең 20.12.2019 № 617 боерыгы

белән билгеләнгән, 2019 елның 20 декабреннән соң беренче тапкыр, аларны төзү вакытыннан алып, яңа күчемсез милек объектларын төзүне тыюны булдырмый торган чаралар тәмамлануга кадәр төзелгән Әгерҗе елгасы янында Әгерҗе шәһәре чикләрендә аренда түләвен исәпләүне туктатырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, вакытлы матбугат басмасы «Татмедиа» ААҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе — А.Р. Вәлиев